**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 10 сентябрь № 625

г. Казань

Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче, 2015 ел, 01 декабрь, 911 нче, 2016 ел, 22 июнь, 425 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.4 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алиментлар түләүдән качарга тырышу белән бәйле ата-аналарны Федераль суд приставлары хезмәте органнары эзләү;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җинаять кылган өчен ата-аналарны җинаять җаваплылыгына тарту;»;

3.6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«банкта яки бүтән кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, балага айлык пособие билгеләү турында гариза (балага айлык пособиене банк яки бүтән кредит оешмасы аша алганда);»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бала (балалар) туу турында таныклык күчермәсе – баланың (балаларның) тууы Татарстан Республикасыннан читтә дәүләт теркәвенә алынган очракта;»;

3.8 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алиментлар түләүдән качарга тырышу белән бәйле ата-аналарны эзләү турында Федераль суд приставлары хезмәте органнарыннан белешмә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«җинаять кылган өчен ата-аналарны җинаять җаваплылыгына тарту турында эчке эшләр органнарыннан белешмә;»;

3.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар яки ышанычнамә нигезендә алар вәкаләтләр биргән затлар гариза белән мөрәҗәгать иткәндә шәхесне таныклый торган документ күрсәтә.»;

3.11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр – баланың (балаларның) тууы Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракларда;

физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләүче) тарафыннан Россия Федерациясе Пенсия фондыннан күчерелгән түләүләр һәм бүтән бүләкләүләр суммасы турында мәгълүматлар;

баланы тәрбиягә алган гаиләгә бирү һәм аны тәрбиягә алган ата-анасына бирелергә тиеш бүләкләү суммасы турында мәгълүматлар;

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукын чикләү турында мәгълүматлар.»;

3.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.15. Балага айлык пособие бирү гариза бирүченең, баланың (балаларның) үлеме, ата-аналарны ата-ана хокукыннан мәхрүм итү яки ата-ана хокукларын чикләү, баланы (балаларны) опекага бирү, 18 яшькәчә баланың (балаларның) кияүгә чыгуы (өйләнүе) яки эмансипациясе белән бәйле тулы хокук алуы, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән гражданның яшәү урынын үзгәртүе белән бәйле туктатыла.»;

3.18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.18. Балага айлык пособие биргәндә гаиләнең җан башына уртача кереме

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарында билгеләнгән тәртиптә исәпләнә.»;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән гражданнарның ризалыгы булганда балага айлык пособие билгеләү әлеге Нигезләмәнең 3.11 пунктындагы сигезенче абзацта күрсәтелгән, балага айлык пособие билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән айга кадәр соңгы алты ай өчен Россия Федерациясе Пенсия фондында булган мәгълүматлар нигезендә башкарыла.»;

3.20 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче
карары белән расланды

**Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибе**

Бу Тәртип «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән балага айлык пособие билгеләгәндә Татарстан Республикасында гаиләнең җан башына уртача керемен исәпкә алу һәм исәпләү кагыйдәләрен билгели.

**1. Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган гаилә составы**

1.1. Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган гаилә составы (алга таба – гаилә составы) балага айлык пособие билгеләү турында гариза тапшырылган көнгә билгеләнә.

1.2. Гаилә составына түбәндәгеләр кертелә:

өйләнешкән ата-ана (уллыкка, кызлыкка алучылар), шул исәптән аерым яшәүчеләр һәм аларның даими яшәү урыны буенча яки вакытлыча тору урыны буенча алар белән бергә яшәүче яки аларның берсе белән яшәүче балигъ булмаган балалары;

ялгыз ата-ана (уллыкка, кызлыкка алучы) һәм аның даими яшәү урыны буенча яки вакытлыча тору урыны буенча үзе белән бергә яшәүче балигъ булмаган балалары;

өйләнешмәгән, даими яшәү урыны буенча яки вакытлыча тору урыны буенча бергә яшәүче ата-ана (уллыкка, кызлыкка алучылар) һәм аларның алар белән бергә яшәүче балигъ булмаган балалары.

Опекада (попечительлектә) булган, Россия Федерациясе законнары нигезендә опекада (попечительлектә) булган балаларны карап тотуга акча түләнмәгән балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә аның ата-анасы (ата-анасының берсе), яшәү (тору) урыннарына бәйсез рәвештә балигъ булмаган ир һәм кыз туганнары һәм бала үзе исәпкә алына.

Аерым яки бергә яшәүләренә бәйсез рәвештә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә балага айлык пособиене алучының ире (хатыны) булган гражданнар керемнәре исәпкә алына.

1.3. Гаилә составына түбәндәгеләр кертелә:

18 яшькәчә балалар, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә тулы хокуклылык алганда;

ата-аналарының аларга мөнәсәбәттә ата-ана хокуклары чикләнгән яисә ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән балалар;

тулысынча дәүләт тәэминатында булган затлар (белем алу белән бәйле тулысынча дәүләт тәэминатында булган затлардан тыш);

сак астына алу рәвешендә чикләү чарасы кулланылган иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәүче затлар, шулай ук суд карары белән мәҗбүри дәваланудагы затлар;

сержантлар, старшиналар, солдатлар яки матрослар сыйфатында чакыру буена хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләр, шулай ук хәрби һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белемнең хәрби белем бирү оешмаларында укучы һәм хәрби хезмәт үтү турында контракт төземәгән хәрби хезмәткәрләр;

опекадагы (попечительлектәге) балалар;

законнарда билгеләнгән тәртиптә хәбәрсез югалган дип танылган гражданнар.

## 2. Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача айлык керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре

2.1. Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача айлык керемен исәпләгәндә гаилә керемено түбәндәгеләр кертеп исәпләнә:

а) хезмәткә түләү системасында каралган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 нче карары нигезендә уртача эш хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган түләүләр;

б) хезмәт законнарында каралган очракларда саклана торган уртача эш хакы;

в) дәүләт яки иҗтимагый вазыйфаларны үтәгән вакытта дәүләт органы яки иҗтимагый берләшмә түли торган компенсация;

г) эштән чыкканда түләнә торган пособие, отставкага киткәндә түләнә торган компенсация, оешманы бетерү, хезмәткәрләре санын яки штатын кыскарту белән бәйле эштән чыкканда эшкә урнашу чорында саклана торган эш хакы;

д) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнүдән керемнәр, крестьян (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат оештырмыйча гына хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәрне дә кертеп;

е) социаль түләүләр:

пенсияләр, компенсация түләүләре (эшкә сәләтсез гражданнарны тәрбияләүне гамәлгә ашыручы эшләмәүче эшкә сәләтле затларга компенсация түләүләреннән тыш);

пенсионерларны өстәмә айлык матди тәэмин итү;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белемнең белем бирү оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча йөреп уку рәвешендә укучы аспирантларга һәм югары белемнең белем бирү оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына, дини белем бирү оешмаларында укучыларга түләнә торган стипендияләр, матди ярдәм,

студентлар, аспирантлар һәм докторантларга алар медицина күрсәтмәләре буенча академик ялда булу чорында бирелә торган компенсация түләүләре;

эшсезлек буенча пособие;

эшсез гражданнарга матди ярдәм һәм бүтән түләүләр;

эш белән тәэмин итү органнары җибәрүе буенча һөнәри белем алу һәм өстәмә һөнәри белем алу чорында гражданнарга түләнә торган стипендия һәм матди ярдәм;

иҗтимагый эшләрдә катнашучы эшсез гражданнарга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарга алар вакытлыча эшләрдә катнашкан чорда түләүләр;

14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарга алар вакытлыча эшләрдә катнашкан чорда түләүләр;

вакытлыча эшкә сәләтсез булу буенча пособие;

йөклелек һәм бала табу буенча пособие;

йөклелекнең башлангыч вакытында медицина учреждениеләренә исәпкә баскан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие;

бала яшь ярымга җиткәнче аны тәрбияләү буенча айлык пособие;

хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә тора торган һәм бала 3 яшькә җиткәнче аны тәрбияләү буенча ялда булган гражданнарга айлык компенсация түләүләре;

чакыру буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрнең баласына айлык пособие;

хәрби хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәткәрләрнең аерым категорияләре балаларына айлык пособие;

опекадагы (попечительлектәге) балаларны карап тотуга түләнә торган акча;

вазыйфаларын түләүле башкаручы опекуннарга (попечительләргә) бирелә торган түләү;

мәктәпкәчә белем бирү оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен компенсация;

даими кеше каравына (ярдәменә, күзәтчелегенә) мохтаҗ 18 яшькәчә инвалид балаларга айлык акчалата түләү;

бер үк вакытта туган өч һәм күбрәк балаларны бала яшь ярымга җиткәнче тәрбияләүче гаиләләргә пособие;

гражданнарга торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә бирелә торган субсидияләр (шул исәптән субсидия ташламалар);

гражданнарның аерым категорияләренә торак урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә компенсация;

контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары (ирләре) белән бергә җирлекләрдә яшәү чорында эшләмәскә мәҗбүри булган яки белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмау сәбәпле эшкә урнаша алмаган һәм билгеләнгән тәртиптә эшсезләр дип танылган хатынына (иренә), шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары (ирләре) иренең (хатынының) хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартлары белән бәйле балалары сәламәтлекләре торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда, әгәр медицина оешмасы бәяләмәсе буенча аларның балалары даими карап торуга мохтаҗ булса, айлык пособие;

ерактагы гарнизоннарда һәм җирлекләрдә Россия Федерациясе эчке эшләр органнары һәм җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкче составы затларының эшләмәүче хатыннарына, аларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге булмаганда, айлык компенсация түләве;

отставкага чыккан судьяларны айлык гомерлек хезмәт хакы;

җитештерүдәге бәхетсез очраклардан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү буенча айлык иминләштерү түләүләре;

хәрби җыеннарга чакырылган хәрби хезмәткәр яки граждан хәрби хезмәт вазыйфаларын үтәгәндә һәлак булган (үлгән), яисә хәрби травма нәтиҗәсендә үлгән очракта гаиләсенең һәр әгъзасына түләнә торган айлык акчалата компенсация;

ж) милек хокукында гаиләнеке (аның аерым әгъзаларыныкы) булган мөлкәттән керемнәр, аларга түбәндәгеләр керә:

күчемсез мөлкәтне (җир кишәрлекләрен, йортларны, фатирларны, дачаларны, гаражларны), транспорт һәм бүтән механик чараларны, продуктлар эшкәртү һәм саклау чараларын сатудан һәм арендага (наемга) бирүдән керемнәр;

шәхси ярдәмче хуҗалыктан алынган җимешләр һәм продукцияне сатудан керемнәр:

з) керемнәрнең бүтән төрләре, аларга түбәндәгеләр керә:

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары һәм җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре, Россия Федерациясе таможня органнары һәм хокук саклау хезмәтенең башка органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими характердагы өстәмә түләүләре һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән азык-төлек белән тәэмин итү;

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан, хокук саклау хезмәтенең башка органнарыннан чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие;

Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эш өчен түләү;

эш бирүче үз хезмәткәрләренә, шул исәптән инвалидлык буенча яки яшь буенча пенсиягә чыгу белән бәйле эштән киткәннәренә күрсәтә торган матди ярдәм;

Россия Федерациясе автор хокукы һәм чиктәш хокуклар турында законнар нигезендә, шул исәптән мираска бирү автор шартнамәләре буенча алына торган автор түләүләре;

акцияләр буенча керемнәр һәм оешма милке белән идарә итүдә катнашудан башка керемнәр;

гаилә әгъзалары ала торган алиментлар;

банктагы кертемнәр буенча процентлар;

мираска бирелгән һәм бүләк ителгән акча.

## 3. Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача айлык керемен исәплләгәндә исәпкә алынмый торган керемнәр төрләре

3.1. Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача айлык керемен исәпләгәндә гаилә керменә түбәндәгеләр керми:

дәүләт социаль ярдәме турында законнар нигезендә күрсәтелә торган дәүләт социаль ярдәме;

пенсиягә социаль өстәмә түләү;

әлеге гаиләдә яшәмәгән затларны карап тоту өчен түләнә торган алиментлар;

I төркем инвалидын, дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими тәрбиягә мохтаҗ яки 80 яшен тутырган карт кешене тәрбияләүне тормышка ашыра торган эшләмәүче эшкә сәләтле затларга айлык компенсация түләүләре;

18 яшькәчә инвалид баланы яки I төркем бала чактан инвалидны тәрбияләүне гамәлгә ашыручы эшкә сәләтле эшләмәүче затларга айлык түләүләр;

айлык акчалата түләү (шул исәптән пенсионерларга юлда йөрү өчен);

ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан затларга юлда йөрүгә субсидия;

ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан затларга түләүләр: белем бирү учреждениесеннән чыкканда бер тапкыр пособие, белем бирү учреждениесеннән чыкканда өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алуга бер тапкыр пособие, өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие, туклануга айлык пособие;

18 яшькә кадәр өч яки күбрәк баласы булган, тәрбиягә алганнарын да кертеп, гаиләләрдән укучыларга юлда йөрүгә айлык субсидия;

18 яшькә кадәр өч яки күбрәк баласы булган, тәрбиягә алганнарын да кертеп, гаиләләрдән 6 яшькә кадәр бала өчен дарулар сатып алуга субсидия;

бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие;

баланы гаиләгә тәрбиягә биргәндә бер тапкыр бирелә торган пособие;

вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә бер тапкыр бирелә торган пособие;

вакцинадан соң өзлегүләр барлыкка килгәндә ай саен бирелә торган пособие;

чакыру буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие;

күмүгә социаль пособие;

техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган түләүләр;

«Россиянең мактаулы доноры» яки «СССРның мактаулы доноры» күкрәк билгесе белән бүләкләнгән затларга еллык акчалата түләү;

кешенең тормышына һәм сәламәтлегенә, аның шәхси мөлкәтенә һәм аның гаилә әгъзаларының уртак милкендәге мөлкәткә китерелгән зыянны кайтаруга бер тапкыр түләнә торган иминләштерү түләүләре, шулай ук медицина-социаль экспертиза дәүләт хезмәте учреждениесе карары нигезендә медицина, социаль һәм һөнәри тернәкләндерүгә өстәмә чыгымнар белән бәйле айлык суммалар.

## 4. Балага пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме зурлыгын исәпләү

4.1. Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме барлык кирәкле документлар белән балага айлык пособие билгеләү турында гариза бирелгән айга кадәр соңгы алты календарь айга билгеләнә (алга таба – исәпләү чоры).

4.2. Исәпләү чорында гаиләнең җан башына уртача кереме гаиләнең айлык уртача берләштерелгән керемен гаилә әгъзалары санына бүлү юлы белән исәпләнә.

Исәпләү чорында гаиләнең айлык уртача берләштерелгән кереме аның барлык гаилә әгъзаларының уртача айлык керемнәре суммасына тигез була.

Һәр гаилә әгъзасының уртача айлык кереме аның исәпләү чоры эчендә алынган керемнәре суммасын ул әлеге керемнәрне алган әлеге исәпләү чорының айлары санына бүлү юлы белән билгеләнә.

## 5. Балага пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә керемнәрнең аерым төрләрен исәпкә алу үзенчәлекләре

5.1. Һәр гаилә әгъзасының керемнәре физик затлар кеременә салым исәпләнгәнгә кадәр исәпкә алына.

5.2. Гражданнар чит ил акчасында алган керемнәр әлеге керемнәрне фактта алган көндә билгеләнгән Россия Федерациясе Үзәк банкы курсы буенча сумнарга яңадан санап карала.

5.3. Гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләгәндә һәр гаилә әгъзасының акчалата алынган керемнәре суммасы исәпкә алына.

5.4. Хезмәт өчен түләү системасында каралган һәм эш нәтиҗәләре буенча бер ай өчен түләнә торган эш хакы суммасы, компенсация һәм стимуллаштыручы характердагы түләүләрне дә кертеп, аны фактта алган айда исәпкә алына.

5.5. Түләүле ял суммасы түләүле ял чорына туры килә торган айлар санына бүленә һәм исәпләү чоры туры килә торган айлар өчен җыелма керемгә кушылып исәпләнә.

5.6. Вакытлыча хезмәткә яраксызлык буенча пособие җыелма керем составында аны фактта алу аенда исәпкә алына, йөклелек һәм бала табу буенча түләүле ял чорына туры килә торган айлар санына бүленгән йөклелек һәм бала табу буенча пособиедән тыш, һәм исәпләү чорына туры килә торган айларга җыелма керемгә кушып исәпләнелә.

5.7. Сезонлы, вакытлы һәм вакытлы хезмәт шартнамәләре буенча башкарыла торган башка төр эшләргә түләү, граждан-хокукый характердагы шартнамәләрне үтәүдән керемнәр суммалары алар алынган айлар санына бүленә һәм исәпләү чорына туры килә торган айларга җыелма керемгә кушып исәпләнелә.

5.8. Эш бирүчеләр – физик затлар белән төзелә торган шартнамәләр буенча эшләүче гаилә әгъзаларының керемнәре тиешле шартнамә күчермәләре нигезендә билгеләнә һәм тиешле шартнамәдә күрсәтелгән түләү суммасыннан чыгып, ул күчерелгән айлар санына бүленеп исәпләнелә һәм исәпләү чорына туры килә торган айларга җыелма керемдә исәпкә алына.

5.9. Оешмалар яки бүтән эш бирүчеләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә булган, тулы булмаган эш вакытында эшләгән гаилә әгъзалары керемнәре түбәндәгечә билгеләнә торган шартлы айлык эш хакыннан чыгып исәпләнелә:

фактта күчерелгән уртача көнлек эш хакы зурлыгы (моның өчен әлеге айда фактта эшләнгән вакыт өчен күчерелгән эш хакы фактта эшләнгән көннәр санына бүленә) керем күчерелгән айдагы эш көннәре санына тапкырлана.

Оешмалар яки бүтән эш бирүче белән хезмәт һәм аңарга тиңләштерелгән мөнәсәбәтләрендә булган, алар өчен эш (хезмәт) урыны булган һәм эш хакы саклanмыйча ялда булган гаилә әгъзалары керемнәре (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 128 статьясындагы өченче – сигезенче абзацларда санап кителгән эш хакын сакламыйча яллар бирү очракларыннан тыш) мондый ял чорында хезмәткәрнең тариф ставкасының (окладының) өчтән ике өлеше күләмендә шартлы эш хакы зурлыгыннан чыгып исәпләнелә.

5.10. Шәхси ярдәмче хуҗалыкта алынган җимешләр һәм продукцияне сатудан алынган керем җир мәйданының бер сутыеннан чиста керем нормативын җир мәйданының сутыйлар санына тапкырлау юлы белән билгеләнә.

Чиста керем нормативы шәхси ярдәмче хуҗалыкның җир мәйданы зурлыгы ун сутыйдан артып киткән очракта кулланыла.

Чиста керем нормативы түбәндәге очракта нольгә тигез була:

әгәр шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы, 18 яшьтән өлкән барлык гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) I яки II төркем инвалидлар һәм (яки) 65 яшьтән өлкән затлар булса;

әгәр гаиләнең бер әгъзасы инвалид бала булса;

шәхси ярдәмче хуҗалык бер елдан кимрәк алып барылган очракта.

Татарстан Республикасында чиста керем нормативы шәхси ярдәмче хуҗалыкта бер сутый җир мәйданыннан алынган җимешләр һәм продукцияне сатудан алынган кыйммәттә ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана.

5.11. Салым салуның гадиләштерелгән системасыннан, салым салуның патентлы системасыннан файдаланучы, бердәм авыл хуҗалыгы салымын түләүче булган шәхси эшмәкәрләр керемнәре, шулай ук адвокатлар, нотариуслар һәм шәхси практика белән шөгыльләнүче бүтән затларның керемнәре алар тапшырган керемнәрне һәм чыгымнарны исәпкә алу китабы нигезендә исәпкә алына.

Исәпләнгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын кулланучы шәхси эшмәкәрләрнең керемнәре алар бирә торган салым декларациясе кысаларында исәпләнелә.

Керемнәр һәм чыгымнар исәбе булмаганда, шулай ук шәхси эшмәкәр салым турында законнар нигезендә салым органына бирә торган документларда керемнәрнең, шулай ук чыгымнарның ноль мәгънәсе күрсәтелсә, шәхси эшмәкәрнең җыелма кеременә муниципаль район (шәһәр округы) буенча җан башына уртача акчалата керем зурлыгына тиң булган, әмма Татарстан Республикасында җан башына уртача акчалата керем зурлыгыннан артмаган шартлы керем зурлыгы кертелә.

5.12. Гаилә әгъзалары ала торган алиментлар суммалары алар фактта кергән айдагы җыелма керемдә исәпкә алына.

Элеккеге ир һәм хатын арасында балигъ булмаган балаларына алимент түләү турында килешү, алимент түләтү турында суд карары булмаган очракта җыелма керем составына алиментларның шартлы күләме кертелә. Алиментларның шартлы күләме ай саен исәпләү чорында исәпләнә һәм бер балага исәпләгәндә Татарстан Республикасында билгеләнгән һәм балага пособие бирү турында гариза бирү

датасында гамәлдә булган балага яшәү минимумы зурлыгыннан 100% тәшкил итә.

5.13. Опекадагы (попечительлектәге) ятим балалар кеременә Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә билгеләнгән пенсияләр суммасы, хезмәттә зыян алу нәтиҗәсендә туендыручысын югалту белән бәйле эш бирүчеләр түли торган зыянны каплау суммалары, ятим балаларны карап тотуга бирелә торган айлык акчалата түләүләр суммалары кертелә.

Ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар һәм нигезле сәбәпләр аркасында үзләренең ата-ана вазыйфаларын үти алмаган чорда ата-аналарның опекун билгеләү турында гаризалары нигезендә опекага бирелгән балалар кеременә Россия Федерациясе пенсия законнары нигезендә билгеләнгән пенсияләр суммасы, хезмәттә зыян алу нәтиҗәсендә туендыручысын югалту белән бәйле эш бирүчеләр түли торган зыянны каплау суммалары, ятим балаларны карап тотуга бирелә торган айлык акчалата түләүләр суммалары, шулай ук ата-аналар керемнәре һәм бу балаларны карап торуга алына торган алиментлар кертелә.

Опекадагы яки попечительлектәге, шул исәптән тәрбиягә алган гаиләләрдә тәрбияләнүче  балалар керемен билгеләгәндә опекуннар (попечительләр) керемнәре исәпкә алынмый.

Опекунның (попечительнең) керемен билгеләгәндә опекадагы (попечительлектәге) балалар кереме исәпкә алынмый.

5.14. Гаилә әгъзаларының исәпләү чоры дәвамында хезмәт эшчәнлегеннән һәм федераль законнарда билгеләнгән бүтән төр эшчәнлектән керемнәре булмау гаилә әгъзалары түбәндәге категорияләрнең берсенә каравын раслый торган документлар тапшырганда нигезле дип таныла:

хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә булган һәм 3 яшькәчә бала тәрбияләү буенча ялда булган эшкә сәләтле зат;

I төркем инвалиды, инвалид бала, 80 яшен тутырган яки медицина оешмасы бәяләмәсе буенча даими тәрбиягә мохтаҗ булган карт кешесе булган гаилә әгъзасын тәрбияләүне тормышка ашыра торган, федераль законнар нигезендә айлык компенсация түләвен алучы  эшкә сәләтле зат;

гомуми белем бирү оешмасында яисә йөреп уку рәвешендә һөнәри белем бирү оешмасында яки югары белемнең белем бирү оешмасында укучы эшкә сәләтле зат;

20 һәм күбрәк атна йөклелек срогы белән медицина оешмасында исәптә торучы эшкә сәләтле зат.

---